РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

***Постановление*** ***Карар***

**29.09.2021** **г.Чистополь** **189**

Чистай шәһәре Башкарма комитетының
2018 елның 27 июнендәге 139 номерлы
карары белән расланган Чистай шәһәре
территориясендә ваклап сату челтәренең
стационар булмаган сәүдә объектларын һәм
җәмәгать туклануының вакытлыча объектларын
урнаштыру турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында" 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 27 июнендәге 139 номерлы карары белән расланган Чистай шәһәре территориясендә ваклап сату челтәренең стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануының вакытлыча объектларын урнаштыру турында Нигезләмәгә, кушымта нигезендә, яңа редакциядә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http://chistopol.tatarstan.ru/ һәм хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталында https://pravo.tatarstan.ru// урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чистай шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Ф.М. Садыйковка йөкләргә.

Шәһәр Башкарма
комитет җитәкчесе И.Ф. Рәхимов

Чистай шәһәре Башкарма
комитетының 2021 елның 29
сентябрендәге 189 номерлы
карарына кушымта

Чистай шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына шартнамә буенча түләү күләмен билгеләү
МЕТОДИКАСЫ

Чистай шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына килешү буенча түләү күләмен исәпләү формуласы:

S= C xКмест. xKs.
xVврем., монда:
S - куллану чорында махсуслаштырылган стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына килешү буенча түләү күләме (сум/урын);
C - стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына килешү буенча түләүнең база күләме (сум/урын);
Кмест. - объектның территориаль урнашуын исәпкә алучы коэффициент;
Ks. - объектның мәйданын исәпкә алучы коэффициент;
Vврем. - стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру өчен урын бирелә торган айлар саны. Әгәр рөхсәт 1 айдан кимрәк вакытка бирелә икән, 1 атна 0,25 дип санала, ә 1 көн 0,03 дип санала.

Чистай шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру хокукы өчен шартнамә буенча түләүнең база күләме
ТАБЛИЦАСЫ

| **N т/б** | **Исемлек** | **База башлангыч бәясе (С) (сум/урын) аена** |
|---|---|---|
| 1. | Азык-төлек товарлары (шул исәптән җәмәгать туклануы): | 1000 |
| | Ит гастрономиясе | 500 |
| | Балык һәм балык продуктлары | 500 |
| | Автоцистернадан тере балык | 500 |
| | Алкогольсез салкынча эчемлекләр, соклар, куас, төрелмәдәге туңдырма (тәмәке һәм сыра сатмыйча) | 1000 |
| | Икмәк һәм икмәк-күмәч әйберләре | 300 |
| | Сөт һәм сөт продуктлары | 300 |
| | Автоцистернадан пастеризацияләнгән сөт | 300 |
| | Яшелчә-җиләк-җимеш, бакча культуралары | 2000 |
| 2. | Азык-төлек булмаган товарлар: | |
| | Басма продукция (шул исәптән театр һәм билет кассалары) | 500 |
| | Сувенирлар, уенчыклар, балалар уеннары, халык һөнәрчелеге эшләнмәләре, аттракционнар | 1000 |
| | Чәчәкләр, күпьеллык һәм берьеллык үсемлекләр, үсентеләр | 1000 |
| | Чыршы базары | 2000 |

| | | |
|---|---|---|
| | Утырту материаллары | 1000 |
| | Кәрәзле элемтә тоташтыру хезмәтләре, лоток сәүдәсе | 2000 |
| | Кием-салым, галантерея, хуҗалык товарлары, аяк киеме һ. б. | 1000 |
| 3. | Көнкүреш хезмәтләре | 1000 |
| 4. | Башка хезмәтләр | 1000 |

Чистай шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә челтәре объектларының мәйданы коэффициентлары
ТАБЛИЦАСЫ

| **N т/б** | **Объект исеме** | **Мәйдан коэффициентлары (Ks.)** |
|---|---|---|
| 1. | 60 кв. метрдан артык мәйданлы стационар булмаган объект | 3 |
| 2. | 30 һәм 60 кв. метрга кадәр булган стационар булмаган объект | 2,5 |
| 3. | 20 һәм 30 кв. метрга кадәр булган стационар булмаган объект | 2 |
| 4. | 10 һәм 20 кв. метрга кадәр булган стационар булмаган объект | 1,4 |
| 5. | 10 кв. метрдан ким булмаган стационар булмаган объект | 0,8 |
| 6. | Бочка (цистерна), сәүдә автоматы | 0,5 |
| 7. | Стационар булмаган сәүдә мәйданчыгы (бер территория белән берләшкән 3 һәм аннан да күбрәк объект) | Сәүдә объектлары саны |

<*> Стационар булмаган мәйдан өчен мәйдан коэффициенты (Ks.) бу мәйданчыкта каралган сәүдә нокталары саны дип санарга. Шул ук вакытта мәйданчыкны оештыручы (өстәмә түләүсез) Чистай шәһәр Башкарма комитетында һәр стационар булмаган объектка теркәү номерларын (рөхсәт кәгазьләрен) алырга тиеш, аның сәүдә субъекты белән килешү төзи, сатучыга минималь документлар комплекты кушып, тиешле гариза (аны компания яки ИП + Федераль салым хезмәтеннән бурыч булмау турында белешмә).
* * * > Стационар булмаган объектлар булмаган лоток сәүдәсе мәйданчыклары өчен сатучыларны өстәмә теркәү таләп ителми. Мондый мәйданчыкны оештыручы үз территориясендә тәртип һәм чисталык өчен тулы җаваплылык тота.

Чистай шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә челтәре объектларының урнашу урыны, җәмәгать тукланув коэффициентлары
ТАБЛИЦАСЫ

| Зона номеры | Урамнар исеме | урнашу коэфффициенты (К урын) |
|---|---|---|
| 1. | шәһәрнең Үзәк өлеше урамнары | 2,0 |
| 2. | Сәгать заводы поселогы, Медиклар йорты, **2 нче микрорайон** урамнары | 1,5 |
| 3. | Водников поселоклары, Тегермән мәйданы, Җиһаз фабрикасы, Автовокзал, Текә тау урамнары | 1,0 |